**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Колбай-Мораса ав. **КАРАР**

«25» август 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Кече Колбай-Мораса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 5 сентябрендә 09 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Колбай-Мораса авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ленин һәм Заречная урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2023 елның 5 сентябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мораса авылы Мәдәният йорты бинасында Колбай-Мараса авылында Мәктәп һәм Зеленая урамнарында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2023 елның 5 нче сентябрендә 11 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мораса авылы, Ленин урамы, 30нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылының Пионер һәм Тукай урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2023 елның 5 сентябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мораса авылы, Ленин урамы, 30нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мораса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылының Яр буе урамы, Мичурин, Садовая урамнарында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча дүртенче гражданнар җыенының этабын уздыруны билгеләргә:

- Колбай-Мораса авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең 2022 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы карары;
- Колбай-Мораса авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең 2022 елның 18 ноябрендәге 6 номерлы карары.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен бүләргә.

6. Колбай-Мораса авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыруны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Трактор сатып алуга җыелган 2023 елгы гражданнарның үзара салым кертүнең 532580 сум 00 тиен (биш йөз утыз ике мең биш йөз сиксән сум 00 тиен) күләмендә калган акчасын БЕЛАРУС 82.1 тракторы өчен тагылмалы җиһазлар сатып алуга кулланырга ризамы».

| | |
|---|---|
| «РИЗА» | «КАРШЫ» |

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин